**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**06.09.2019** **№ 1520**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы яшьләр сәясәте муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтләренә түләү шартлары турында”, 2018 елның 15 ноябрендәге 2406 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарсатн Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 14 августындагы 665 номерлы карары белән расланган, яшьләр сәясәте дәүләт оешмаларының һәм Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлыгына ведомство карамагында булган типик булмаган аерым оешмаларның хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында”, 2019 елның 21 июнендәге 505 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты, КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы яшьләр сәясәте муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтләренә түләү шартлары турында”, 2018 елның 15 ноябрендәге 2406 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Әлеге карарның 1 пункты рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән соң) үз көченә керә һәм 2018 елның 1 нче ноябреннән соң килеп туган хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.».

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы яшьләр сәясәте муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтләренә түләү шартлары турында”, 2018 елның 15 ноябрендәге 2406 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы яшьләр сәясәте муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) V бүлектә:

а) 2.4 пунктының 6 абзацында «26,5» саннарын «41,0» саннарына алмаштырырга;

б) 6 нчы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6 нчы таблица

Хезмәт интенсивлыгы өчен надбавкалар күләме

| Төркемнең һөнәри квалификациясе исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Надбавка күләме, процент |
|---|---|---|
| Беренче дәрәҗәдәге уку-укыту-ярдәмче персонал хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | - | 41,0 |
| Икенче дәрәҗәдәге уку-укыту-ярдәмче персонал хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | беренче | 41,0 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | беренче – дүртенче | 41,0 |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | беренче | 46,0 |
| | икенче | 49,0»; |

в) 4.4 пунктының 6 абзацында «26,5» саннарын «41,0» саннарына алмаштырырга;

г) 11 нчы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11 нче таблица

Хезмәт интенсивлыгы өчен надбавкалар күләме

| Төркемнең һөнәри квалификациясе исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Надбавка күләме, процент |
|---|---|---|
| “Техник башкаручылар һәм ярдәмче состав артистлар вазыйфалары” һөнәри квалификация төркеме | барлык вазыйфалар | 41,0 |
| “Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография вазыйфалары” һөнәри квалификация төркеме | аккомпаниатор, костюмнар бүлеге җитәкчесе | 49,0 |
| | түгәрәк, үзешчән берләшмә, кызыксынулар буенча клуб җитәкчесе, мәдәни оештыручы | 61,0 |

| | | |
|---|---|---|
| “Алдынгы звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография вазыйфалары” һөнәри квалификация төркеме | барлык вазыйфалар | 49,0 |
| “Мәдәният, сәнгать һәм киноматография учреждениеләре җитәкче составы вазыйфалары” һөнәри квалификация төркеме | барлык вазыйфалар | 49,0»; |

2) VIII бүлекнең 8 пунктының 5 абзацында «10» саннарын «20» саннарына алмаштырырга.

3. Әлеге карарны атарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы һәм Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар, 1 пункттан кала, рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән соң) үз көченә керә һәм 2019 елның 1 нче гыйнварыннан соң килеп туган хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла икәнлеген билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Сабирҗанов Р.Р.ка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф.Шәйдуллин